КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 21 июль г.Казань № 637

«Invest in Tatarstan» имидж кампаниясен тормышка ашыруга бәйле оешмаларның чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану хакында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм «Invest in Tatarstan» имидж кампаниясен тормышка ашыруга бәйле оешмаларның чыгымнарын каплау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Invest in Tatarstan» имидж кампаниясен тормышка ашыруга бәйле оешмаларның чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин